ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№231 от «05» 09 2019 г.

« 2015-2020 елларга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында коррупциягә
каршы сәясәтне гамәлгә ашыру"
муниципаль программасына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү, коррупциячел хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итүче чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 10 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» Дәүләт программасын раслау турында» 512 санлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру». муниципаль программасын раслау турында" 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән 1622 нче санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пункттагы «2015-2020» санын «2015-2022» санына алмаштырырга»;

әлеге карар белән расланган «2015-2020 елларга коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасында (алга таба-Программа):

атамада «2015-2020» санын «2015-2022» санына алмаштырырга»;

программа паспортында:

Программаның исемендәге «2015-2020» саннарын «2015 – 2022» саннарына алмаштырырга;

«программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында "«2015-2020" саннарын «2015-2022 саннары белән алмаштырырга»;

«Программаны финанслау күләмнәре, аларны үтәү еллары буенча бүлү белән» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм Мамадыш муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Моннан тыш, Программа чараларын тормышка ашыру өчен

чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны файдалану күздә тотыла”.

программаның V бүлегендәге беренче, икенче абзацында «2020 елга» сүзләрен «2022 елга кадәр» сүзләренә алмаштырырга»;

Программаның кушымтасындагы “«2015-2020» санын «22015-2022» санына алмаштырырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 ноябрендәге «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 578 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов